**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын әзерләү һәм аларны Татарстан Республикасы Рәисенә бирү, Татарстан Республикасы Рәисе указларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2023 елның 23 октябрендәге 729 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын әзерләү һәм аларны Татарстан Республикасы Рәисенә бирү, Татарстан Республикасы Рәисе указларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибенең 2 нче пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа уналтынчы абзац өстәргә:

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую турында;»;

б) уналтынчы – егерменче абзацларны тиешле тәртиптә унҗиденче – егерме беренче абзацлар дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе регламентын раслау турында» 2024 елның 20 гыйнварындагы 44 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 30 мартындагы 232 номерлы, 2024 елның 19 сентябрендәге 729 номерлы һәм 2026 елның 10 апрелендәге 286 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе регламентының 12.8 пунктына, аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен

вакытлыча башкаручыны билгеләп кую турында указлары проектлары Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Территорияләр белән эшләү идарәсе һәм Дәүләт-хокук идарәсе белән берлектә билгеләнгән тәртиптә эшләнә, килештерелә һәм Татарстан Республикасы Рәисенә кул куярга бирелә.».

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 09 июль
№ 552